5. Доганы тавышны бик көчәйтмичә генә кылалар.Тавыш бик әкрен дә, бик каты да булмасын. *«Раббыгызга яшерен һәм ялвару хәлендә дога кылыгыз, ялварыгыз»* дигән аять («әл-Әгъраф» сүрәсе, 55 нче аять) дога кылганда тавышыбызның нинди булырга тиешлеген аңлата. Пәйгамбәребез исә: *«Әй, инсаннар! Сез дога кылган Аллаһы саңгырау да, телсез дә түгел. Белегез, Ул сезнең белән атланган хайваннарыгызның муены арасындадыр (сезгә шулкадәр якындыр)»*, – дигән. Коръән-Кәримдә: *«Без аңа шаһ тамырыннан да якынрак»*, – диелгән («Каф» сүрәсе, 16 нчы аять). Монда Пәйгамбәр хәзрәтләре бу аятьне искә төшереп, Аллаһының кешегә якынлыгын белдерү өчен «ул сезнең белән атланган хайваннарыгызның муены арасындадыр» дию доганы түбән тавыш белән кылуның кирәклегенә ишарәт өчен әйткән булса кирәк. Моннан аңлашылганча, дога кылган кеше тавышын ишетелерлек кадәр генә күтәрергә тиеш.

Дога кабул булуның кайбер сәбәпләре:

1) Сәфәрдә булу. Пәйгамбәр галәйһис-сәлам әйткән: *«Өч доганың кабул булуына шик юк: рәнҗетелүченең догасы, мосафирның догасы, атаның балалары өчен догасы».* Сәфәр озак дәвам итсә, аның кабул булачагының ихтималы тагын да арта. Чөнки мондый очракларда кеше туган якларын сагына, төрле авырлыклар кичерә. Шул сәбәпле аның итагате арта. Ә итагать – дога кабул булуның әһәмиятле сәбәпләреннән берсе.

2) Кулларны югары күтәрү. Бу югарыда искә алынган дога кылу кагыйдәләренә керә. Пәйгамбәр галәйһис-сәлам әйткән: *«Дөреслектә, Аллаһы оялчан һәм юмарт. Аңа таба үзенең кулларын күтәргән кеше аларны төшерсә һәм аның өметләре акланмаса, Аллаһыга оят була».* Яңгыр сорап дога кылганда, Пәйгамбәр галәйһис-сәлам култык астының аклыгы күренерлек дәрәҗәдә кулларын күккә таба күтәргән. Ә Бәдер сугышында мөшрикләргә каршы ярдәм сорап дога кылганда, ул кулын шул хәтле югары күтәргән, хәтта җилкәләреннән япмасы төшеп киткән.

3) Аллаһыга ялварып дога кылу. Бу очракта Аллаһыны еш искә алу күз алдында тотыла. Пәйгамбәр галәйһис-сәлам әйткән: *«Бәндә дүрт тапкыр «Әй, Раббым!» дип әйткәннән соң, Аллаһы: «Мин ишетәм сине, әй бәндәм, сора һәм Мин сиңа шуны бирәчәкмен!» – дияр».*

*(“Дин вә йола” газетасыннан)*

***БӘЕТ***

**Хөрмәтле редакция хезмәткәрләре! “Кыйбла” кушымтасында киленем Румиягә багышланган бәетне бастырып чыгарсагыз иде. Иремнең сеңелесенең улы Рөстәмгә бик күп кайгы кичерергә туры килде. Әле өч ел элек кенә бер-бер артлы әнисе, әтисе һәм 24 яшьлек сеңелесе якты дөнья белән хушлаштылар. Һәм минә күптән түгел аның ишегенә тагын бер зур кайгы шакып керде, 25 ел бергә гомер иткән хатыны Румия 47 яшендә яман шеш чиреннән вафат булды. Бердәнбер уллары Марат әнисез калды. Алар Отрадный шәһәрендә яшиләр. Киленебезгә багышлап бәет яздым, шуны сезгә дә җибәрәм.**

**Саимә МОРЗАХАНОВА.**
Гали авылы,
Похвистнево районы.

## *Румия киленебезгә*

*Бу кадәр авыртулардан*
*Сула-кибә башладым.*
*Тик сиздермәскә тырыштым,*
*Эчемә йотып яшәдем.*

*Җанны алучы җәза -*
*Яман шеш үзен белдерде.*
*Хөкем карары куркыныч,*
*Үләчәгем билгеле.*

*Авыртуга түзеп булмый,*
*Көтеп ятам үлемне.*
*Яшәргә озак калмады,*
*Ал тизрәк җанымны.*

*Күз яшьләрем йотылды,*
*Әйтәсе сүзләрем онытылды.*
*Иреннәрем ябылды,*
*Әҗәлем тәнемә кагылды.*

*Тереләй киптем, көчем юк*
*Тәнемне күзгатырга.*
*Күзләремдә — газап уты,*
*Тырышасыз юатырга.*

*Ай-йолдызлар, кояш та юк,*
*Күз алдымда кара төн.*
*Әҗәл пышылдады колагыма:*
*“Бүген синең соңгы көн”.*

*Ирем, улымны бик җәллим,*
*Ятим булып калалар.*
*Елый-елый соңгы тапкыр*
*Йөземне ачып карарлар.*

*Булмә уртасына салырсыз*
*Җаным чыккан гәүдәмне.*
*Күргән берегез җәлләп елар*
*Бары калган шәүләмне.*

*Суык гәүдәмне кочаклап*
*Үксеп-үксеп еларлар.*
*Кабер әзер инде диеп,*
*Ашыгып-ашыгып юарлар.*

*Төшләрегезгә керермен,*
*Барыгызны сагынып.*
*Рөхсәт булса, кайтыр идем*
*Сезнең янга ашкынып.*



# Белемгә, мәгълүматка нигезләнеп эш итү кирәклеге турында

Коръән-Кәримгә күрә, инанучы кеше - тормышның һәр өлкәсендә белемгә, мәгълүматка нигезләнеп эш итүче кеше. Коръән Аллаһының барлыгы, берлеге, гыйлем һәм хикмәтенә булган инануыбызны уйлау, фикер йөртү һәм мәгълүмат алу юлы белән ныгытуыбызны тели. Җирнең һәм күкләрнең барлыкка килүе турында уйлавыбызны боеручы аятьләрнең максатларыннан берсе нәкъ менә бу. Түбәндәге аятьләр бу җәһәттән игътибарны җәлеп итә:

*“Галим кеше Аллаһының җәзасыннан курка (чөнки ул - укыган, белемле, надан кеше исә Аллаһыны бар дип тә белми)”* (Фатыйр,28). *“Белгән белән белмәгән бер булырмы?”* (Зүмәра, 9).

Коръән уйлап, дәлилгә таянып сөйләшүебезне тели. Мәсәлән, ышанмыйча, Аллаһының китабын кире кагучыларга: *“Әгәр сез хаклы икән, сүзегезгә дәлил китерегез”* (Нәмел, 64) дип боера. Изге китабыбыз *“Белмәгән нәрсәгә иярмә”* (Исра, 36) дип, ялган һәм ялгыш мәгълүмат җиткерүне тыя.

Коръән фикергә, уйлауга таянып хөкем чыгармауның дөрес булмавын катгый рәвештә хәтерләтә. Уйламыйча сөйләшүчеләрне түбәндәгечә тасвирлый: *“Аларның күбесе фаразлардан башкага буйсынмас. Шик юктыр ки, фараз хакыйкатьтән коткармас”* (Юныс, 36).

Китабыбыз Коръәнгә күрә, дөрес һәм ялгышны аермыйча традицияләргә сукырларча ияру һәм «әтиләребез шулай эшли иде» дип әйтү кешеләргә зур куркыныч тудыра. Тикшермичә, өйрәнмичә торып сукырларча кемгә дә булса ияреп эш итүчеләргә аятьтә түбәндәгеләр искәртелә: *“Кяферләргә: “Аллаһыдан иңгән Коръәнгә генә иярегез дигәч, алар: “Юк, без аталарыбыз нинди юлдан йөргән булса, шул юлны тотачакбыз”, - диделәр. Аталары бернәрсә дә аңламыйча, дөрес юлны тапмаган булсалар?”* (Бәкара,170).

Изге китабыбыз безне тикшеренергә чакырганда тәҗрибә һәм гыйльми мәгълүматларга таянуның әһәмиятенә ишарәт итә.

Коръән кешене уйларга чакыра. Акылын кулланучы кеше һәм Аллаһыга кулай ышаныр, һәм дә Аллаһы кушкан кебек әхлаклы булыр. Хәзер тәкъдим ителәчәк аятьләр бу теманы яктыртучы үрнәкләрдән бары тик берничәсе: *“Бу Коръән Аллаһының бердәнбер Тәңре икәнен белсеннәр өчен вә зиһенле кешеләр уйлап-аңлап, үгет алсыннар дип, кешеләргә иңдерелгән белем китабы”* (Ибраһим,52).

*«Рәсүлем, сиңа бу изге китапны, аятьләребезне аңласыннар вә зиһенле кешеләр үгетнәсыйхәт алсыннар дип иңдердек”* (Сад, 29).

*«Әй Мөхәммәд, бу аның белән кисәтү һәм инанучыларга үгет булсын өчен сиңа иңдерелгән китап»* (Әграф,1).

Коръән-Кәрим кешегә тормышны аңларга ярдәм итә, кеше һәм җиһанны кемнең яралтуы, ни өчен яралтуын өйрәтә. Бернәрсәнең дә максатсыз, мәгънәсез яралтылмавын белдерә. Коръәндә Аллаһы болай дип боера:

*«Болай гына, эше булмаганнан эш булсын, дип кенә безне яралтты һәм, чынлап та, ул безне үз хозурына кайтармас дип өметләнәсезме?»*

*«Без Күкне дә, Җирне дә, алар арасындагыларны да шаярып өчен генә хасил итмәдек»* (Әнбия,16).

Коръән кешегә төп теләк-кызыксынуларын ничек тәэмин итә алачагын күрсәтә, җәмгыять һәм тирә-якка ничек яраклашырга өйрәтә. Моның өчен кешеләргә максатлар куя. Бу - кулы белән дә, теле белән дә ышанычлы кеше булу максаты. Бу максатка ирешү өчен Коръән кешегә ярдәм итә. Кешеләргә тормышны мәгънәле кылучы төп кыйммәтнең нәрсә булуын өйрәтә. Нәрсәләргә ышанырга, ничек инанырга һәм ышанганнары белән ничек гармонияле яшәячәген күрсәтә.

Коръән кешегә дөнья күзаллавын тәкъдим итә. Шушы дөнья күзаллавына ия булган кеше үзе һәм дөнья белән бәйле буларак дөрес рәвештә уйлап эш итә. Бу рәвешле камил әхлаклы кешелеккә ия була. Шуңа күрә дә Коръән кешенең көндәлек тормышында мөһим урын алып тора.

Коръән-Кәрим җиһанның матди булуы кадәр рухи ягының булуын да белдерә. Зур дөньяның рухи үлчәмен хәбәр итүче аятьләрнең берничәсенең мәгънәсе шушы рәвешле:

*“Җиде кат күкләрдәге, Җир һәм Җир өстендәгеләрнең барчасы (фәрештәләр, җеннәр, кешеләр) Аллаһыга тәсбих (мактау) әйтә. Аны мактамаган беркем дә, бернәрсә дә (хәтта җансыз җисемнәр дә) юк. Аяныч ки, сез (мөшрикләр) аларның тәсбихен аңламыйсыз”.*

*“Күрмисезмени, күктәгеләр дә, җирдәгеләр дә, кояш та, ай да, йолдызлар, таулар, агачлар, хайваннар вә инсаннарның күбесе Аллаһыга сәҗдә итә”.*

Шул нәрсә күренә ки, безнең җансыз дип белгән барлыкның да хәтта Аллаһы белән дәвам итүче мөнәсәбәте бар. Алар да үз вәзгыятьләренә яраклы рәвештә Аллаһыны телгә ала. Бу бик мөһим. Моны Коръәннән тыш башка бер урында өйрәнү мөмкинлегебез юк.

Коръән-Кәрим җиһандагы хайваннар һәм үсемлекләр турында да кешегә мәгълүмат бирә:

*«Атланып йөрер өчен, мәртәбәләр (тантаналар) өчен атларны, качырларны, йөкташыр хайваннарны (дөяне) яралттык».*

*«Җир йөзендә сезнең кебек өммәт булып яшәмәгән һичбер хайван вә Күк йөзендә канатлары белән очкан һичбер кош токымы юктыр. Китапны кимчелекле итмәдек (анда барысы да язылган, бернәрсә дә төшереп калдырылмаган). Соңрак барысы да кубары-*

№ 44 (1171), 27 октябрь 2012 ел